ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2020 Балык Бистәсе штп. №247пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле әһәмияттәге юлларында юл төзелеше объектларын файдалануга кабул итү буенча комиссия төзү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен һәм алардан килгән зыянны киметү буенча чараларны тормышка ашыру турында” 2019 елның 18 декабрендәге 1167 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле әһәмияттәге юлларында юл төзелеше объектларын файдалануга кабул итү турындагы Нигезләмәне расларга (кушымта №1).

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле әһәмияттәге юлларында юл төзелеше объектларын файдалануга кабул итү буенча комиссия составын расларга (кушымта №2).

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Исланов Р. Л.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2020 илнының 23 ноябрендәге
247 номерлы карарына
кушымта №1

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле әһәмияттәге юлларында юл төзелеше объектларын файдалануга кабул итү турында**

**Нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының һәм аларның бүлемтекләренең төгәлләнгән төзелешләрен (реконструкцияләнүен, капиталь ремонтлануын), шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы (алга таба – Заказчы) милкенә караган әлеге юллардагы күперләрне, юлүткәргечләрне һәм башка юл корылмаларын (алга таба – юлларны, объектларны) файдалануга кабул итү тәртибен билгели.

Юлларны һәм объектларны файдалануга кабул итү, төзелеш барышы чорында Россия Федерациясендә гамәлдә булган закон актлары, төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, стандартлар, инструкцияләр, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Мөстәкыйль әһәмияткә ия булган һәм аларны карап тору, сервис хезмәте күрсәтү һәм транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өчен кирәкле җиһазлар белән тәэмин ителгән, төзү (реконструкцияләү, капиталь ремонтлау) тәмамланган юллар һәм объектлар файдалануга кабул ителергә тиеш.

3. Юллар һәм объектлар районның Кабул итү комиссиясе тарафыннан файдалануга кабул итүгә куела.

Юлларны яки объектларны файдалануга кабул итү кабул итү комиссиясе акты белән рәсмиләштерелә (1 һәм 2 кушымталар).

4. Аерым очракларда, эшләрне башкару процессында заказчы яки күзәтчелек органнарының җитди кисәтүләре булганда кабул итү контроле буенча сынауларның шактый күләме белән зур катлаулылыктагы юл яки объектны кулланылышка кабул итүгә кадәр кабул итү комиссиясе күрсәтүенә юлның яисә объектның әзерлеген билгеләү өчен Заказчы карары нигезендә эшче комиссия билгеләнә, эшче комиссия актын төзелә (кушымта 3).

Эшче комиссия составы һәм аның эш тәртибе, подрядчы белән килештереп, Заказчы тарафыннан билгеләнә. Эшче комиссия материаллары кабул итү комиссиясенә Заказчы тарафыннан күрсәтелә.

5. Җитешсезлекләре, дефектлары булган яки транспорт-эксплуатация күрсәткечләре гамәлдәге нормаларга туры килми торган юлларны яки объектларны файдалануга кабул итү рөхсәт ителми.

6. Юл яки объектны кабул итү датасы булып дәүләт кабул итү комиссиясе актына кул кую датасы санала.

Бу датадан юл яки объектны файдалануның гарантия срогы башлана.

## Кабул итү комиссиясе

7. Юллар һәм объектлар Заказчы билгели торган кабул итү комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан файдалануга кабул ителә.

8. Төбәк һәм федераль автомобиль юлларына тоташкан яисә аларны кисеп үтүче гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын кабул итү комиссиясе составына юлларны балансында тотучының вәкиле мәҗбүри тәртиптә кертелергә тиеш.

9. Комиссия, юлның яисә объектның характерына һәм катлаулылыгына карап, вакытыннан алда, әмма юлны яисә объектны тапшыру срогына кадәр 1 айдан да соңга калмыйча билгеләнә. Шул ук вакытта комиссия эшен башлау һәм төгәлләү даталары тәгаенләнергә тиеш.

10. Юлларны яисә объектларны кабул итү комиссиясе составына Заказчы, эксплуатация оешмасы, подрядчы, юл яисә объект урнашкан территориядәге җирле үзидарә органы администрациясе, проектлаштыручы, Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлегенең юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе вәкилләре кертелә. Кирәк булганда, әлеге комиссияләр составына шулай ук субподряд оешмалары һәм башка ведомстволар һәм күзәтчелек органнары вәкилләре дә кертелергә мөмкин.

11. Кабул итү комиссиясе рәисе итеп Заказчы вәкиле билгеләнә.

12. Комиссия әгъзаларын алыштыруның нигезле зарурлыгы булган очракта, аның составына башка предприятиеләр, оешмалар, ведомстволарның вәкилләрен кертү турында карарны кабул итү комиссиясе рәисе кабул итә.

## Юл һәм объектны файдалануга кабул итүгә әзерләү

13. Комиссия эше өчен материаллар әзерләүгә җаваплылык Заказчыга йөкләнә.

Подрядчы, подряд шартнамәсе нигезендә, юл төзелеше тәмамлангач, заказчыга билгеләнгән срокларда, объектта эшнең тәмамлануы һәм объектның кабул итүгә әзерлеге турында рәсми хәбәрнамәне дә кертеп, кирәкле документларны һәм юлны файдалануга кертүнең планлаштырылган датасына кадәр 1 айдан да соңга калмыйча – Комиссиянең эшләү датасы турындагы тәкъдимне тапшырырга тиеш.

14. Эшнең төгәлләнүе һәм объектның подрядчыдан кабул итүгә әзерлеге турында хәбәрнамәне алганнан соң, Заказчы кабул итү комиссиясе составын 2 бүлектә тәгаенләнгән тәртиптә билгеләү турында карар кабул итә.

15. Кирәк булганда, төзелгән юлны яки объектны файдалануга кабул иткәнче, Заказчы, гамәлдәге кагыйдәләр, норматив документлар нигезендә,

тикшерүләрнең тулы комплексын яки аларның диагностикасын башкаруны, алга таба алынган нәтиҗәләрне Заказчыда саклана торган мәгълүматларның үзәкләштерелгән банкына тапшыруны оештыра.

Тәҗрибә уңаеннан һәм беренче тапкыр кулланылган конструкцияләре булган күперләр файдалануга кабул ителгәнче билгеләнгән тәртиптә сынаулар узарга тиеш.

Файдалануга тапшырыла торган башка күперләрнең (зур торыкларга ия, шулай ук төп терәк элементларның күп булганнарының) сынаулары "Күперләр һәм торбалар. Тикшерену һәм сынау кагыйдәләре" нең (СНиП 3.06.07-86) 1.5 һәм 1.6 пунктлары нигезендә үткәрелергә тиеш.

16. Үткәрелгән тикшерүләр һәм диагностика нәтиҗәләре буенча аларны уздырган оешма Заказчыга төзелгән юлның яисә объектның расланган проект-смета документациясе һәм файдалану нормаларына туры килүе турында, юл яки объектны файдалануга кабул итү мөмкинлеге турында нәтиҗәләр белән бәяләмә тапшыра.

17. 3 нче кушымтага ярашлы рәвештә материаллар Заказчы тарафыннан кабул итү комиссиясе эшли башлаганчы 3 көннән дә соңга калмыйча формалаштырыла.

18. Заказчы юлны яки объектны кулланышка кабул итә башлаганчы, 10 көннән дә соңга калмыйча кабул итү Комиссиясенең эшли башлау вакытын билгели һәм бу хакта Комиссия әгъзаларына хәбәр итә.

## Кабул итү комиссиясе эше

19. Кабул итү комиссиясе эшен аның рәисе оештыра. Комиссия эше өчен кирәкле шартларны Заказчы тудыра.

20. Заказчы төзелеше (реконструкциясе, капиталь ремонты) тәмамланган юлны яисә объектны һәм аның файдалануга кабул итүгә әзерлеген раслый торган документларны (3 нче кушымта) Комиссиягә күрсәтә.

21. Юллар яки объектлар визуаль тикшерү, кирәкле үлчәүләр үткәрү һәм проба үрнәкләрен алу өчен уңайлы чорда файдалануга кабул ителергә тиеш.

Автомобиль юлында тотрыклы кар катламы булган очракта Комиссия эше рөхсәт ителми.

22. Кирәк булган очракта, тикшерү яки диагностика комплексын, шулай ук объектны сынап карауны уздыручы органнарның уңай бәяләмәләре булмаганда, төзелгән юлларның һәм объектларның ныклыгын, тотрыклылыгын, ышанычлылыгын һәм экологик куркынычсызлыгын киметә торган проекттан чигенүләр булганда, транспорт чаралары хәрәкәте иминлеге дәрәҗәсе, шулай ук проект оешмасы белән килештерелмәгән проект-смета документларыннан чигенүләр булганда юлларны яки объектларны кулланышка кабул итү рөхсәт ителми.

23. Файдалануга кабул итү турындагы Актка Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имза куела. Актка Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан куллар куелган булса, объект кабул ителгән дип санала.

Аерым фикере булган Комиссия әгъзалары аны гамәлдәге закон һәм норматив актларга сылтамалар булган нигезләүләр белән кабул итү акты кушымтасында язма рәвештә бәян итәләр.

24. Әгәр Комиссия юлны файдалануга кабул итү мөмкин булмау турында карар кабул итсә, кабул итү акты урынына гамәлдәге закон һәм норматив актларга сылтама белән барлык кирәкле нигезләмәләрне, шулай ук юлны гамәлгә кертүне тәэмин итү буенча тәкъдим ителә торган чараларны үз эченә алган, дәлилләнгән бәяләмә төзелә.

Күрсәтелгән бәяләмәгә Комиссиянең барлык әгъзалары да кул куярга һәм күчермәсе подрядчыга җибәрелергә тиеш.

Дәлилләнгән бәяләмәдә объект файдалануга кабул ителмәүдә гаепле булган конкрет предприятиеләр һәм оешмалар күрсәтелә.

25. Файдалануга кабул ителмәгән юлларда һәм күперләрдә гомуми файдаланудагы транспорт чаралары хәрәкәте рөхсәт ителми. Автомобиль юлы составына керүче төзелеше тәмамланган аерым корылмалар, төзелеш процессында аларны кулланышка алу зарурлыгы булганда, эшче комиссияләр тарафыннан алар әзер булган саен файдалануга кабул ителә, аннары объектны тулаем кабул итүче кабул итү комиссиясенә күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле әһәмияттәге юлларында юл төзелеше объектларын файдалануга кабул итү турындагы Нигезләмәгә кушымта №1

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле әһәмияттәге юлларында юл төзелеше объектларын файдалануга кабул итү турында кабул итү комиссиясе**

**АКТы**

20___ елның_____ Балык Бистәсе штп.

20___ елның________дә_____ номерлы_________________________________
( боерыгы, карары нигезендә Комиссияне билгеләгән органның аталышы)
___________________________________билгеләнгән кабул итү комиссиясе составы:

Рәисе _________________________________________________________
(фамилия, И.А.и.) (вазыйфасы)

һәм комиссия әгъзалары-вәкилләре:

Заказчының:_____________________________________________________
(фамилия, И.А.и.) (вазыйфасы)

Подрядчының:____________________________________________________
(фамилия, И.А.и.) (вазыйфасы)

Проектлаучының:_________________________________________________
(фамилия, И.А.и.) (вазыйфасы)

Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча ЮХИДИ бүлегенең:__________________________________________________________
(фамилия, И.А.и.) (вазыйфасы)

Җирле үзидарә администрациясенең:__________ ________________________
(фамилия, И.А.и.) (вазыйфасы)

(югарыда телгә алынганнардан тыш, Комиссия әгъзалары сыйфатында катнашучы башка оешмаларның, учреждениеләрнең барлык вәкилләре дә күрсәтелә)

**БИЛГЕЛӘДЕ:**

1.Заказчы_________________________________________________тарафыннан
(оешманың исемен (аталышын) күрсәтергә)

файдалануга тапшырырга кабул итүгә тәкъдим ителде. ________________________________________________________________________

( юл төзелеше объектының (участогының) атамасын, аның административ әһәмиятен,

_______________________________________________________________________,

төзелеш төрен (реконструкция, капиталь ремонт)

________________________________________________________________________

һәм урнашкан урынын (өлкә, район) күрсәтергә)

2 2.Төзелеш түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә апшырылды:

подрядчы ___________________________________________________________,

(оешма исемен күрсәтергә)

түбәндәге эшләрне башкарды____________________________________________

______________________________________________________________ һәм

(эш төрләрен күрсәтергә)

субподряд оешмалары ___________________________________________

(барлык оешмаларны һәм һәр оешма тарафыннан башкарылган эшләрне күрсәтергә,

________________________________________________________________________

оешмалар саны өчтән артык булганда, аларны әлеге актка бирелгән кушымтада күрсәтергә)

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

3. Төзелешкә проект-смета документациясен түбәндәге проектлаучы тарафыннан башкарылды:_____________________________________________

(оешма исемен күрсәтергә)

_______________________________________________________________________,

( документациянең өлешләрен яки бүлекләрен күрсәтергә)

һәм субподряд оешмалары тарафыннан башкарылды: ________________________________________________________________________

(барлык оешмаларны һәм һәр оешма тарафыннан башкарылган документациянең өлешләрен яки бүлекләрен күрсәтергә; оешмалар саны өчтән артык булганда, аларны әлеге актка бирелгән кушымтада күрсәтергә)

4. Проект-смета документациясе расланды______________________________

________________________________________________________________________

(документның исемен һәм автомобиль юлы (бүлемтеге) буенча проект-смета документациясен раслаган (кабаттан раслаган) органның исемен (аталышын), документның исемен күрсәтергә)

20___ елның ____ ____________ №_____.

5. Төзелеш 20___ елның _____ ___________-дә (-да) чыгарылган ___ номерлы карар (боерык) нигезендә үткәрелде.

________________________________________________________________________

(карарны чыгарган оешманың исемен (аталышын) күрсәтергә)

6. Төзү-монтаж эшләре түбәндәге срокларда гамәлгә ашырылды::
эшләр башланды ________________________;
(ай, ел)
эшләр төгәлләнде ____________________.
(ай, ел)

7. Кабул итү комиссиясенә тәкъдим ителде (күрсәтелде): ___________________
______________________________________________________________________
(3 нче кушымта нигезендә документация)
8. Кулланышка кабул итүгә тәкъдим ителгән автомобиль юлы түбәндәге төп күрсәткечләргә ия:
а) юлның техник категориясе __________________________
б) юлның озынлыгы __________________________________ км.
в) җир полотносының киңлеге ______________________________ м.
г) машиналар йөрү өлешенең киңлеге _________________________________ м.
д) габаритлары, ясалма корылмаларның исәпләнгән йөкләнешләре
______________________________________________________________________
е) юл киемнәре (капламнары) (күперләр һәм юлүткәргечләрдән гайре)
______________________________________________________________________
ПК дан алып ПКга кадәр проект буенча калынлыгы күрсәтелгән конструктив кием (каплам) катламнары
Искәрмә_______________________________________________________________
ж) юл һәм автотранспорт хезмәтләре биналары һәм корылмалары
______________________________________________________________________
з) табигатьне саклау чаралары ________________________________________.

9. Автомобиль юлының җибәрү комплекслары (чиратлары) кабул итү комиссияләре тарафыннан кулланышка кабул ителде
______________________________________________________________________
( җибәрү комплексы исемнәрен күрсәтергә)

10.Эксплуатацияләүче оешма һәм шартнамә шартлары: _____________________
______________________________________________________________________

11. Расланган проект-смета документлары буенча смета бәясе:

Барлыгы: __________________________________________ мең сум, шул исәптән:
Төзү-монтаж эшләре ____________________________________________ мең сум.
12.Файдалануга алынган төп фондның смета бәясе _________________ мең сум.
13. Фактик чыгымнар ( заказч өчен) ______________________________ мең сум.

**Объектны тапшырды:** **Объектны кабул итте:**
**Подрядчы:_________________________**
**Заказчы:_____________________________**
**(имза) (Ф.И.А.и.)** **(имза) (Ф.И.А.и.)**

Кабул итү комиссиясе тәкъдим ителгән документацияне карады, натурада күпер кичүен (күперне, юлүткәргечне) карап чыкты, башкарылган эшләрнең проектка туры килүен билгеләде, өстәмә үлчәүләр һәм сынаулар уздырды:_________________________________________________________
(үлчәү һәм сынау төрләре атамасы)

**КАБУЛ ИТҮ КОМИССИЯСЕ КАРАРЫ**

Кабул итүгә тәкъдим ителгән_____________________________________________
_____________________________________________________________________
( юл төзелеше объекты, участогы исеме)

Файдалануга кабул итәргә.

Актка кушымталар:

1. _________________
2. ________________

Комиссия рәисе _____________ ________________________________
(имза) (фамилия, И.А.и.)

Комиссия әгъзалары: _____________ ___________________________
(имза) (фамилия, И.А.и.)

_____________ ___________________________
(имза) (фамилия, И.А.и.)

_____________ ___________________________
(имза) (фамилия, И.А.и.)

_____________ ___________________________
(имза) (Фамилия, И.А.и.)

_____________ ___________________________
(имза) (Фамилия, И.А.и.)

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле әһәмияттәге юлларында юл төзелеше объектларын файдалануга кабул итү турындагы Нигезләмәгә кушымта №2

**Кабул итү комиссиясенең күпер кичүен (күперне, юлүткәргечне) файдалануга кабул итү турында**
**АКТЫ**

20 __ елның __ Балык Бистәсе штп.

20___ елның ___ ___________-дә(-да) ____ номерлы боерык (карар) нигезендә билгеләнгән кабул итү комиссиясе (составы)_________________________________ _____________________________
(үзенең боерыгы, карары белән Комиссияне билгеләгән органның аталышы)

рәисе___________________________________________________________
(фамилиясе, И.А.и., вазыйфасы)
Һәм комиссия әгъзалары – түбәндәгеләрнең вәкилләре:
Заказчының:_____________________________________________________
(фамилиясе, И.А.и., вазыйфасы)

Подрядчының:___________________________________________________
(фамилиясе, И.А.и., вазыйфасы)

Проектлаучының:_________________________________________________
(фамилиясе, И.А.и., вазыйфасы)
Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча ЮХИДИ бүлегенең:_____________________________________________________
(фамилиясе, И.А.и., вазыйфасы)

Җирле үзидарә администрациясенең: ______________________________
_______________________________________________________________________
(фамилиясе, И.А.и., вазыйфасы)
(югарыда телгә алынганнардан тыш, Комиссия әгъзалары сыйфатында катнашучы башка оешмаларның, учреждениеләрнең барлык вәкилләре дә күрсәтелә)

**БИЛГЕЛӘДЕ:**

1. Заказчы ___________________________________________ тарафыннан
(оешманың исемен (аталышын) күрсәтергә)

кабул итүгә тәкъдим ителде (күрсәтелде)____________________________
______________________________________________________________________
(күпер кичүенең, күпернең, юлүткәргечнең, аларның чиратларының, юлның исемен (аталышын), километрын, төзелеш төрен (реконструкцияләү, капиталь ремонтлау) һәм урнашу урынын (район) күрсәтергә)

2.Төзелеш түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә апшырылды:

Подрядчы_______________________________________________________ ,
(оешманың исемен (аталышын) күрсәтергә)
ул түбәндәге эшләрне башкарды: _________________________________________,
(эш төрләрен күрсәтергә)
Һәм түбәндәге субподрядчы оешмалар катнашында:
______________________________________________________________________
(барлык оешмаларны һәм һәр оешма тарафыннан башкарылган эшләрне күрсәтергә, оешмалар саны өчтән артык булганда, аларны әлеге актка бирелгән кушымтада күрсәтергә)
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

3. Төзелешкә проект-смета документациясе түбәндәге проектлаучы тарафыннан:_________________________________________________________,
(оешманың исемен күрсәтергә)
башкарды:___________________________________________________________,
( документациянең өлешләрен яки бүлекләрен күрсәтергә)

Һәм субподрядчы оешмалар тарафыннан башкарылды:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(барлык оешмаларны һәм һәр оешма тарафыннан башкарылган документациянең өлешләрен яки бүлекләрен күрсәтергә; оешмалар саны өчтән артык булганда, аларны әлеге актка бирелгән кушымтада күрсәтергә)

4.Проект-смета документациясе расланды__________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(документның исемен һәм автомобиль юлы (бүлемтеге) буенча проект-смета документациясен раслаган (кабаттан раслаган) органның исемен (аталышын), документның исемен күрсәтергә)

20___ елның ____ ____________ №_____.

5. Төзелеш 20___ елның _____ ___________-дә (-да) чыгарылган ___ номерлы карар (боерык) нигезендә үткәрелде.
______________________________________________________________.
(карарны чыгарган оешманың исемен (аталышын) күрсәтергә)

6. Төзү-монтаж эшләре түбәндәге срокларда гамәлгә ашырылды::
эшләр башланды ______________________;
(ай, ел)
эшләр төгәлләнде ____________________

(ай, ел)

7. Кабул итү  комиссиясенә тәкъдим ителде (күрсәтелде):______________
_______________________________________________________________
(3 нче кушымта нигезендә документация)

8.Кулланышка  кабул итүгә тәкъдим ителгән күпер кичүе, күпер түбәндәге төп күрсәткечләргә ия:
юлның  техник категориясе _________________________
күперләрнең озынлыгы __________________________________ м.
күпернең ачыклыгы (тишеге) _____________________________ м.
киңлек буенча габарит ________________________________ м.
сул яктагы тротуарлар ______________ , уң яктан____________
күпернең (юлүткәргечнең) буй схемасы ___________________________
машиналар йөрү өлешенең авышлыгы: буйга ___________, аркылыга _
проект буенча йөкләнешләре  _______________________
күпердәге киртәләр __________, якынлашкандагы _____________
табигатьне саклау чаралары _______________________________________
якын килү озынлыгы _____________________
якын килүдә җир катламының киңлеге ______________________
якын килүдә машиналар йөрү өлешенең киңлеге _____________________
якын килүдә каплам төре ____________________________________ .

9. Кабул итү комиссияләре тарафыннан кулланышка кабул ителгән җибәрү комплекслары  (чиратлары)
______________________________________________
______________________________________________________________________
(җибәрү комплексларының аталышын күрсәтергә)
10. Эксплуатацияләүче оешма һәм шартнамә шартлары:
______________________________________________________________________
11. Расланган проект-смета документлары буенча смета бәясе:
Барлыгы: _________________________ мең сум, шул исәптән:

Төзү- монтаж эшләре ____________________________________ мең сум.
12. Файдалануга алына торган төп фондларның смета бәясе ____ мең сум.
13. Фактик чыгымнар) ( заказчы өчен) ______________________ мең сум.

**Объектны тапшырдым:** **Объектны кабул иттем:**
**Подрядчы:__________________________**
**Заказчы:____________________________**
**(имза) (Ф.И.А.и.)** **(имза) (Ф.И.А.и.)**

Кабул итү комиссиясе тәкъдим ителгән документацияне карады, натурада күпер кичүен (күперне, юлүткәргечне) карап чыкты, башкарылган эшләрнең

проектка туры килүен билгеләде, өстәмә үлчәүләр һәм сынаулар уздырды:_______________________________________________________________

(үлчәү һәм сынаулар төрләренең исеме)

**КАБУЛ ИТҮ КОМИССИЯСЕ КАРАРЫ**

Кабул итүгә тәкъдим ителгән_______________________________________

(күпер кичүе, күпер, юлүткәргеч, комплекс, чират исеме (аталышы)

файдалануга (кулланышка) кабул итәргә.

Актка кушымталар:

1. ___________________
2. __________________

Комиссия рәисе _____________ _____________________________________

Комиссия әгъзалары: ______(имза) (Фамилия, И.А.и.)

________ _________________________________

(имза) (Фамилия, И.А.и.)

_______________ _______________________________

(имза) (Фамилия, И.А.и.)

_______________ _____________________________

(имза) (Фамилия, И.А.и.)

_______________ _____________________________

(имза) (Фамилия, И.А.и.)

_____________ ____________________________

(имза) (Фамилия, И.А.и.)

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле әһәмияттәге юлларында юл төзелеше объектларын файдалануга кабул итү турындагы Нигезләмәгә кушымта №3

**Кабул итү комиссиясенә тәкъдим  ителә (бирелә) торган документлар исемлеге**

**Заказчы документлары**

1. Расланган  проект-смета документациясе.
2. Җир кишәрлегеннән файдалану хокукын дәүләт теркәве турында таныклык.
3. Кабул итүгә куела торган объектның расланган проектка туры килүе һәм аны нормаль эксплуатацияләү мөмкинлекләре турында объектны контрольдә тота торган дәүләт күзәтчелеге органнары бәяләмәләре.
4. Эшләнгән эшләрне (биналарны, корылмаларны, конструктив элементларны) арадагы кабул иткәндә Заказчы (яисә аның күрсәтмәсе буенча) тарафыннан башкарылган контроль үлчәүләр ведомостьлары.
5. Төзелгән юл төзелеше объектының гамәлдәге нормалар нигезендә башкарылган диагностика сынаулары мәгълүматлары.
6. Объектның эксплуатацион оешмасын билгели торган документ.
7. Объектны файдалануга  кабул итү акты проекты.
8. Төзелгән автомобиль юлын тикшерү һәм диагностикалау, күпер кичүен (күперне, юлүткәргечне) сынау үткәргән оешманың файдалануга кабул итү мөмкинлеге турындагы нәтиҗәләре белән бәяләмәсе.

**Подрядчы документлары**

1. Объектның факттагы бәясен исәпләү.
2. Төзү эшләрен башкару хокукына гамәлдәге норматив актлар белән таләп ителә торган рөхсәтнамә (лицензия.)
3. Эшләрне башкару һәм авторлык күзәтчелеге журналлары.
4. Сертификатлар, техник паспортлар, сынау актлары, лаборатор журналлар һәм төзү-монтаж эшләрен башкарганда кулланылган материалларның, конструкцияләрнең Һәм детальләрнең сыйфатын таныклаучы башка документлар һәм башка башкарма-производство документациясе.
5. Башкарма буй профиль.
6.Тапшырыла торган объектның файдалану ышанычлылыгы буенча гарантия паспортлары.
7. Күпергә (юлүткәргечкә) паспорт.
8. Торбаларга карталар.

9. Подряд шартнамәсендә каралган барлык эшләрне төгәлләү һәм объектның кабул итүгә әзерлеге турында хәбәрнамә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2020 елның 23 ноябрендәге 247пи
номерлы карарына кушымта №2

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле әһәмияттәге юлларында юл төзелеше объектларын файдалануга кабул итү буенча комиссия**
**СОСТАВЫ**

1. **Комиссия рәисе** – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе.

2. **Комиссия рәисе урынбасары –** Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары.

**Комиссия әгъзалары:**

3. Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча ЮХИДИ бүлеге башлыгы (килешенү буенча).

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы.

5. Территориясендә юл төзелеше эшләре башкарылган җирлек башлыгы (килешенү буенча).

6. Подрядчы вәкиле (килешенү буенча).